**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы
Карашай-Саклау авыл җирлегенең Чураш авылы торак пунктында
2026 елда үзара салым кертү турында

**2025 елның 15 ноябре** **№ 2**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Карашай-Саклау авыл җирлегенең Чураш авылы торак пунктында гражданнар җыены

**КАРАР БИРДЕ:**

1. 2026 елда Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Карашай-Саклау авыл җирлегенең Чураш авылы торак пунктында I төркем инвалидларыннан, көндезге бүлектә укучы студентлардан тыш, мобилизацияләнгәннәрнең гаилә әгъзалары ,яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1500 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрергә:

1) Торак пункт территориясен төзекләндерү (су башнясын сатып алу һәм урнаштыру, килешү буенча түләү, махсус аренда.техника)

2) Чураш торак пунктында тышкы яктырту урам челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны (урам яктырткычларын сатып алу һәм урнаштыру) ремонтлау

3) Традицион Күмү урыннарын төзекләндерү ( кыргый куаклардан чистарту өчен гербицидлар сатып алу, Чураш авылы зираты)

3. Әлеге карарны Карашай-Саклау авыл җирлеге мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә, Сарман муниципаль районының рәсми сайтында (https://sarmanovo.tatarstan.ru/), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгәннән соң 7 көн эчендә бастырып чыгарырга.

Сарман муниципаль районы
Карашай-Саклау авыл җирлеге башлыгы,
гражданнар җыенында рәислек итүче В.В.Хосниева